КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 сентябрь г.Казань № 852

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшер-ларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшер-ларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 28 февраль, 127 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшер-ларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган вазыйфаларның программа реестрына» сүзләрен «Татарстан

Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган медицина оешмаларында һәм аларның структур бүлекчәләрендә медицина хезмәткәрләренең чираттагы финанс елына бер тапкыр компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган вакантлы вазыйфалары исемлеге (вазыйфаларның программа реестры)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин